**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 7, село Ибраево Каргали, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 7 йорт, Ибрай Каргалы авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 127 28 октябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 26 октябрендәге № 8 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 26 октябрендәге № 8 карарына (Советның 2023 елның 28 сентябрендәге 93 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3%, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш һәм

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш".».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чykканнан соң бер ай узгач кына.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Н.Минһаҗев**